**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Яңа Кишет торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында карар**

**12 ноябрь 2024 ел**

**№5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Яңа Кишет торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

"Сез 2025 елда Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Яңа Кишет авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыелган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән Яңа Кишет авылында яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру);

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү( ремонтлау өчен материаллар алу һәм ремонтлау);

- торак пункт территориясен төзетләндерү (МТЗ 82.1 тракторына прицеплы җиһазлар сатып алуны финанслау (үзбушаткыч тагылма)).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 243 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 127 граждан кертелде.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 127 кеше тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Яңа Кишет торак пунктында гражданнар җыены узды, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. “Сез 2025 елда Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Яңа Кишет авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыелган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән Яңа Кишет авылында яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру);

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү( ремонтлау өчен материаллар алу һәм ремонтлау);

- торак пункт территориясен төзетләндерү (МТЗ 82.1 тракторына прицеплы җиһазлар сатып алуны финанслау (үзбушаткыч тагылма)).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

соравы буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Яңа Кишет авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кишет авыл, Дуслык урамы, 100а йорты адресы буенча, Арча муниципаль районның (http:// arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы ____________ Ф.И.Ахмадуллин
(имза)(имзаның аңлатмасы)